КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 декабрь г.Казань № 1089

2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумын раслау турында

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге үсешнең төп өстенлекләрен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумын расларга.
2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына ел саен 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.
3. 2026 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумын раслау турында» 2022 ел, 7 декабрь, 1296 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 26 октябрь, 1356 нчы карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумын раслау турында» 2022 ел, 7 декабрь, 1296 нчы карары белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2024 ел, 20 август, 675 нче карары.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 декабрь, 1089 нчы
карары белән расланды

2026 – 2028 елларга
Татарстан Республикасының инвестиция меморандумы

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумы (алга таба – Меморандум) 2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге үсешенең төп өстенлекләрен билгели.

1.2. Меморандум инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру өчен раслана һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең стратегик максатына ирешүгә юнәлдерелә.

1.3. Меморандум инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан инвестиция эшчәнлеге планнарын эшләгәндә һәм раслаганда нигез итеп тәкъдим ителә.

1.4. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге белән идарә итү буенча дәүләт сәясәтен эшләү функцияләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы, шулай ук Меморандум нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплылык үзәге – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.

1.5. Инвестицияләр җәлеп итү, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда булышлык итү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча вәкаләтле республика башкарма хакимият органы – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы.

1.6. Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә органы – Татарстан Республикасы Инвестиция советы.

1.7. Меморандум тексты Татарстан Республикасының гавами мәгълүмат ресурслары составына кертелә.

II. Инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре

2.1. 2026 – 2028 елларда Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре:

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указында куелган түбәндәге илкүләм максатлар нигезендә билгеләнгән илкүләм проектларга (программаларга) туры килә торган инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү: халыкны саклап калу, кешеләрнең сәламәтлеген ныгыту һәм иминлеген арттыру, гаиләгә ярдәм итү, һәр кешенең мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру, аның талантларын үстерү, патриотик һәм

социаль җаваплы шәхес тәрбияләү, яшәү өчен уңайлы һәм имин мохит, экологик иминлек, тотрыклы һәм динамикалы икътисад, технологик лидерлык, дәүләт идарәсен һәм муниципаль идарәне, икътисадны һәм социаль өлкәне цифрлы трансформацияләү;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2036 елга кадәр фараз белән 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең пространстволы үсеш стратегиясен раслау турында 2024 елның 28 декабрендәге 4146-р номерлы боерыгы нигезендә билгеләнгән Идел буе федераль округы үсешенең өстенлекле юнәлешләренә, 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган инвестиция проектларын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе регионнары һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү, халыкара икътисадый кооперация пространствосыннан актив файдалану;

инвестиция климатын яхшырту һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга салым ташламалары (шул исәптән махсус инвестиция контрактлары кысаларында) бирү, масштаблы инвестиция проектларын, дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашырганда җир кишәрлекләре арендага торглар үткәрмичә бирү, шулай ук законнар нигезендә инвестиция проектларына ярдәмнең башка рәвешләре аша дәүләт ярдәме күрсәтү;

эшмәкәрлеккә ярдәм итү инфраструктурасын, шул исәптән махсус икътисадый зоналарны, алгарышлы үсеш территорияләрен, инновацион фәнни-технологик үзәкләрне, технопаркларны, индустриаль паркларны үстерү;

экспортка юнәлдерелгән тармакларда проектларны гамәлгә ашыру (импортны алыштыручы товарлар, чимал һәм материаллар);

технологик лидерлыкны тәэмин итүгә ярдәм итә торган проектларны, шул исәптән биотехнологиядә, биоикътисадта гамәлгә ашыру;

нефть-газ химиясе комплексында, радиоэлектроникада, авыл хуҗалыгында һәм медицинада зур югары технологияле проектларны гамәлгә ашыру;

эшкәртү югары дәрәҗәдә булган инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

азык-төлек иминлеген тәэмин итүгә һәм авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыруга, экспорт юнәлешендәге авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

оешмаларны технологик, шул исәптән ясалма интеллект һәм цифрлы платформалы экосистемаларны кулланып үзгәртүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

икътисадта һәм социаль өлкәдә цифрлаштыруны үстерү;

фәнни технологияләр һәм продукция булдыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

фәнни оешмаларның һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының реаль икътисад реаль секторы белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (инженерлык

мәктәпләре, югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында стартап-студияләр, яшьләр фәнни лабораторияләре);

кече инновацион предприятиеләр, кече технологик компанияләр проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

мәгълүмати куркынычсызлык өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыру;

оборона-сәнәгать комплексы проектларын гамәлгә ашыру;

авиа, вертолет, автомобиль төзелешенә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

тимер юл, су, һава транспортын үстерү буенча проектларны гамәлгә ашыру;

партнерлык (ислам) буенча финанслау инструментлары нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

эчке туризм проектларын үстерү.

2.2. Меморандумда билгеләнгән инвестиция сәясәте юнәлешләренә социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләрен һәм аның яңа өстенлекләрен, шулай ук законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

## III. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары

Инвестиция эшчәнлеге субъекты – инвестор, заказчы, подрядчы, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучы һәм инвестиция эшчәнлегендә башка катнашучылар.

## IV. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара бәйләнеше

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлек тәртибе законнар кысаларында билгеләнә һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан эшләнә торган регламентлар белән билгеләнә.

## V. Республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары бурычлары

Меморандумда билгеләнә торган 2026 – 2028 елларга республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының төп бурычлары:

үз компетенцияләре кысаларында республика башкарма хакимият органнары тарафыннан инвестиция һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән иң яхшы төбәк, федераль һәм чит ил тәҗрибәләрен кертүне тәэмин итү;

республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр

перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указын үтәү өчен эшләнгән илкүләм проектларны тәшкил итә торган төбәк проектлар чаралары гамәлгә ашырылуын һәм аларның план буенча максатчан күрсәткечләре күләмнәренә ирешүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында төзелгән килешүләрдә билгеләнгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган күләмнәрен үтәү.